# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“4” декабрь 2025 ел. №1

«Җәмәгать хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 *июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,* 2025 елның 4 декабрендә «Сез 2026 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннантыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- 1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шимбер бистәсендә үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ); (Яңа Шимбер авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));
- 2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 42 (кырык ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 22 (егерме ике) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 22 (егерме ике) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. «Сез 2026 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

   1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шимбер бистәсендә үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ); (Яңа Шимбер авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));

2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.